Мин үземнең карт бабам турында язырга булдым.

Ул - **Зөфәров Нурлыбаян Гыймазетдин улы.**

Бабай 1926 елда Баулы районы Кызыл - Яр авылында туа. Ул мәктәптә гел "5" билгеләренә генә укый. Аның хыялларын тормышка ашырырга сугышы комаучалаган.

18 яше тулгач, 1944 елны бабамны Армия сафларына алалар. Яхшы укуы аның менә шунда кирәк булып чыга. Аны командирлар әзерли торган мәктәпкә җибәрәләр. Укып бетерүгә аны Польшага җибәрәләр.  Ул укчы һәм артиллерия гаскәрләрендә хезмәт итә. Корал командиры була. Ул иптәшләре белән Польшаны бандера бандитларыннан саклаган. Сугыш беткәч тә әле тагын алты ел бабам чит илләрне саклаган, Германияга хәтле барып җиткән. Аның күкрәген орден һәм медальләр бизи.

# Зөфәров Нурлыбаян Гыймазетдин улы



Менә Армиядән кайткач, ул үзенең яшь чагындагы хыялларын тормышка ашыра. Ул нефть һәм газ техникумын бетереп, инженер - технолог булып пенсиягә чыкканчы эшли.



# Минем бабам Җиңү парадында

